**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **23.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге составына керүче, Әлкәй авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру "Җиңү көне", "Сабантуй", "Өлкәннәр көне", "Яңа ел", "Инвалидлар көне";
- Әлкәй авылында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй авылында юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй авылында территорияләрне чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш(щебенка) җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү(чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй авылында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй авылында зиратларга дератизация уздыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлкәй авыл җирлеге Башлыгы С.З.Зиннурова

АЛЬКЕЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002494
КПП 164301001